# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ
(IV чакырылыш)
## КАРАР
IV чакырылышынын 12 утырышы

09 декабрь 2022 ел № 54 Урыссу штп

**«Ютазы районында сәнәгать паркы территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга муниципаль ярдәм күрсәтү турында» 2018 елның 24 декабрендәге 47 номерлы Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Ютазы муниципаль районы территориясендә инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру, предприятиеләргә һәм оешмаларга ярдәм итү, җитештерүне, сәнәгатьне үстерү, эш урыннарын арттыру максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясендә капитал салулар рәвешендә гамәлгә ашырыла торган инвестиция эшчәнлеге турында» 25.02.1999 ел, № 39-ФЗ Федераль закон нигезендә, «Көндәшлекне яклау турында» 26.07.2006 ел, № 135-ФЗ Федераль закон, "Татарстан Республикасында инвестицион эшчәнлек турында" 25.1.1998 № 1872 Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 07.05.1999 № 284 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары, шулай ук Татарстан Республикасы Ютазы районы Советының № 29 от 29.07.2011ел Карары белән расланган «Ютазы муниципаль районында инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга муниципаль ярдәм күрсәтү тәртибе турында» Нигезләмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы районы Советы карар кабул итә:

1. «Ютазы районында сәнәгать паркы территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга муниципаль ярдәм күрсәтү турында» 2018 елның 24 декабрендәге 47 номерлы Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «2022 елга» сүзләрен «2023 елга» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында шартнамә шартларын бозган мизгелдән туктатыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан

Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында “Рәсми Татарстан” дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының законлылык, регламент һәм җирлекләр Советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Башлыгы -
Татарстан Республикасы Ютазы
район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин